Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге
Нептун торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

12 ноябрь, 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең Нептун торак пунктында 2022 елның 12 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 42 (кырык ике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 23 (егерме өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 21 (егерме бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 2 (ике).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2024 елда Нептун торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урынына кадәр юлны ремонтлау» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Екатериновка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Жуков